| “Каралды” | “Килешенде” | “Расланды” |
| --- | --- | --- |
| Методик берләшмә житәкчесе: _____ Гареева А.Х.<br>Беркетмә № 1<br>31 август, 2023 нче ел | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: _____ Гараева С.Р.<br>31 август, 2023 нче ел | «Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе » ГББМБУ директоры: _____ Гайнуллин З.А.<br>Боерык № 88<br>31 август, 2023 нче ел |

**Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе»**
**гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең беренче категорияле татар теле**
**һәм әдәбияты укытучысы Нуруллина Гөлкәй Ринат кызының**
**8 нче сыйныфы өчен туган (татар) телдән “И туган тел,и матур тел”**
**электив курс эш программасы**

Педагогик киңәшмә утырышында каралды.
Беркетмә № 1 31 август, 2023 нче ел.

2023 нче уку елы

## Аңлатма язуы

“И туган тел,и матур тел” дип аталган электив курс программасы - бүгенге татар теленең актуаль темасы. 34 сәгатькә исәпләнгән бу курс 8 сыйныф укучылары өчен бердәм дәүләт имтиханына әзерлек материалы булып тәкъдим ителә. Электив курс программасын Зәкиев М.З., Ганиев Ф.А., Зиннәтуллина К.З. авторлыгындагы “Татар грамматикасы”на нигезләнеп төзедем. Программа мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәрен тирәнтен өйрәнүне, аларны дөрес итеп сөйләмгә кертүне күздә тота.

### Электив курсның актуальлеге:

Лексик-грамматик күнекмәләрне эшләгәндә укучылар авырлык кичерәләр. Бу биремнәрне дөрес эшләү өчен укучыларга бирелгән сүзне текст эчтәлегенә грамматик яктан туры килерлек итеп үзгәртергә кирәк. Укучылар беренчедән җөмләнең мәгънәсен аңларга, аннан соң бирелгән сүзләрдән кирәкле сүз төркемнәре ясап, аларны төрле грамматик формаларга куярга тиешләр. Укучыларның сөйләм телләрен үстерү, җөмлә төзегәндә сүзләрне кирәкле грамматик формаларга куя белү өчен дәресләр саны гына аз. Бу курс укучыларда телгә карата дөрес мөнәсәбәт формалаштыру, телнең лексик-грамматик байлыгыннан дөрес файдаланырга, сүзлек запасын арттырырга ярдәм итәр. Телгә карата теоретик белемнәрне тирәнәйтү, телнең грамматикасын өйрәнү, ныклы күнекмәләр булдыру, практик яктан сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтү бу курсның нигезенә салынган. Электив курс 8 нче сыйныф укучыларын бердәм дәүләт имтиханына әзерләү өчен ярдәмлек булып тора.

### Электив курсның максат һәм бурычлары:

- татар халкына, аның әдәби теленә, тарихына һәм мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү;
- тел аркылы татар халкының тарихын, гореф-гадәтләрен тирәнрәк үзләштерү;
- укучыларның сүзлек хәзинәсен баету;
- укучыда үзлегеннән укуга, өйрәнүгә ихтыяҗ булдыру;
- үз фикерләрен татар телендә, сөйләмә һәм язма рәвештә, эзлекле, җыйнак, төгәл итеп бирергә өйрәтү;
- сөйләмдә сүзләрне грамматик яктан дөрес кулланырга өйрәтү;
- әдәби сөйләм культурасына ия булган шәхес тәрбияләү.

**Электив курсның төп дәрес формалары:**

- лекция;
- лекция-әңгәмә;
- лекция-презентация;
- практик дәресләр.

**Электив курс программасына төп таләпләр:**

- электив курсның, татар теленнән бердәм республика тестына әзерләнгәндә, ярдәмлек буларак хезмәт итүе;
- төрле чыганакларны файдаланып, үзлектән иҗади эш башкару күнекмәләрен формалаштыру;
- сөйләмнең чисталыгын, сафлыгын тәэмин итү.

**Программаның билгеләнеше:**

34 сәгатькә исәпләнгән бу программа 8 нче сыйныф укучыларына тәкъдим ителә, гомуми белем бирү мәктәпләренең гуманитар профильле сыйныфларында кулланыла ала.

**Электив курс буенча укучылар белергә тиешле белем һәм күнекмәләр:**

1. Үз сөйләмеңдә сүзләрне грамматик яктан урынлы куллана белү.
2. Сөйләм этикасы нормаларын белергә тиеш.
3. Үз сөйләмеңдә сүзләрне лексик яктан урынлы куллана белү.
4. Вакытлы матбугат язмаларындагы кимчелекләрне күрә белү.
5. Гади һәм кушма җөмләләрне аеру,аларны сөйләмдә дөрес куллану.

## Тематик укыту планы

| | Тема | Сәгать саны | Үткәрелү көне | | Дәрес төре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт | | |
| 1 | Кереш дәрес.Грамматика нәрсә өйрәнә.Сүз төркемнәре. | 1 | 06.09 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 2 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем.Исемнең килеш белән төрләнеше | 1 | 13.09 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 3 | Тартымлы исемнәрнең килешләр белән төрләнеше. | 1 | 20.09 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 4 | 3 зат берлек,күплек сандагы тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | 27.09 | | Лекция - әңгәмә | практика |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 1,2зат күплек сандагы тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 1 | 04.10 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 6 | Төрле килештәге тартымлы исемнәрне сөйләмгә кертү. | 1 | 11.10 | | Лекция - презентац | практика |
| 7 | Фигыльләр.Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр. | 1 | 18.10 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 8 | Затланышлы фигыльләр.Боерык фигыль,аның ясалышы, төрләнеше, сөйләмдә кулланылышы. | 1 | 25.10 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 9 | Шарт фигыль, аның ясалышы, төрләнеше, сөйләмдә кулланылышы. | 1 | 08.11 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 10 | Хикәя фигыль.Аның заманнары. Хәзерге заман хикәя фигыль. | 1 | 15.11 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 11 | Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыль, зат-сан белән төрләнеше. | 1 | 22.11 | | Лекция - әңгәмә | практика |
| 12 | Билгеле һәм билгесез киләчәк заман хикәя фигыль, зат-сан белән төрләнеше. | 1 | 29.11 | | Лекция - әңгәмә | тест |
| 13 | Затланышсыз фигыльләр.Сыйфат фигыль заманнары,сөйләмдә кулланылышы. | 1 | 06.12 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 14. | Хәл фигыль формалары, аларның сөйләмдә кулланылышы. | 1 | 13.12 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 15 | Инфинитив, аның сөйләмдә кулланылышы | 1 | 20.12 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 16 | Исем фигыль,аның сөйләмдә кулланылышы. | 1 | 27.12 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 17 | Затланышсыз фигыльләрне кабатлау. | 1 | 10.01 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 18 | Кушма җөмләләр. | 1 | 17.01 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 19 | Тезмә кушма җөмләләр. | 1 | 24.01 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 20 | Иярченле кушма җөмләләр. | 1 | 31.01 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 21 | Аналитик иярчен кушма җөмләләрнең бәйләүче чаралары. | 1 | 07.02 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 22 | Синтетик иярчен кушма җөмләләрнең бәйләүче чаралары. | 1 | 14.02 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 23 | Иярчен ия,хәбәр җөмләләр. | 1 | 21.02 | | Лекция-әңгәмә | практика |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | Иярчен аергыч, тәмамлык җөмләләр. | 1 | 28.02 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 25 | Иярчен хәл җөмлә.Иярчен вакыт җөмлә. | 1 | 06.03 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 26 | Иярчен шарт һәм кире җөмләләр. | 1 | 13.03 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 27 | Иярчен урын җөмлә. | 1 | 20.03 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 28 | Иярчен сәбәп,максат җөмләләр. | 1 | 03.04 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 29 | Иярчен рәвеш, күләм җөмләләр. | 1 | 10.04 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 30 | Иярчен аныклагыч җөмлә. | 1 | 17.04 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 31 | Иярченле кушма җөмләләр янында тыныш билгеләре. | 1 | 24.04 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 32 | Туры сөйләм | 1 | 08.05 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 33 | Кыек сөйләм | 1 | 15.05 | | Лекция-әңгәмә | практика |
| 34 | Йомгаклау. | 1 | 22.05. | | Зачет | |

**Файдаланылган әдәбият исемлеге:**


Зәкиев М.З., Ганиев Ф.А., Зиннәтуллина К.З. Татар грамматикасы. III томда., I том- Мәскәү “Инсан”, Казан “Фикер”, 1998 .-507 с.

Валиуллина З.М. Сопоставительная грамматика русского и татарского языков. – Казань, 1968.- 126 с.

Газизов Р.С. Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. – Казань: Таткнигоиздат, 1959.-308 с.: 2-е издание.:Казань, 1966.-368 с.

Ганиев Ф.А. Словообразование как один из разделов татарского языкознания // Тезисы докладов итоговой научной сессии за 1970 г. – Казань: ИЯЛИ, 1971.-С.27-29.

Ганиев Ф.А. Словобразовательная структура слов в современном татарском языке. – Казань,:ИЯЛИ,1972, - С. 45-47.

Ганиев Ф.А. Суффиксальное образование глаголов в современном татарском литературном языке. – Казань : Изд-во КГУ, 1976.-108 с.

Гиганов И. Грамматика татарского языка . – СПб., 1801. -188 с.

Русско –татарский словарь : В 4 т. – Казань : Таткнигоиздат, 1955. -1959.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге : 3 томда. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1977 – 1981.